**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**«Ивашкино авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены карары**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының Ивашкино авыл җирлегенең**
**Әккәрәй торак пунктында гражданнар җыены**
**нәтиҗәләре турында**

20 октябрь 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 20 октябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2024 елда Ивашкино авыл җирлеге Әккәрәй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциясендә булган затлардан, 1 төркем инвалидлардан, ялгыз өлкән яшьтәге һәм 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- Әккәрәй торак пунктында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә (юл кырыйларын чабу, урам-юл челтәрен норматив хәлгә китерү, триммер өчен бензин, запас частьләр сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, трактор өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, чокырларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу, хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга чыгымнар;
- Әккәрәй торак пунктында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.
- Әккәрәй торак пунктында Азат итүче сугышчы һәйкәлен капиталь ремонтлау, проект-смета документациясен әзерләү, һәйкәл территориясен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәтләр өчен түләү;

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 463 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 241 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында 241 катнашучы тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ивашкино авыл җирлегенең Әккәрәй торак пунктында халык җыены **булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.**

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2024 елда Ивашкино авыл җирлегенең Әккәрәй торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциясендә булган затлардан, 1 төркем инвалидлардан, ялгыз өлкән яшьтәге һәм 90 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- Әккәрәй торак пунктында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә (юл кырыйларын чабу, урам-юл челтәрен норматив хәлгә китерү, триммер өчен бензин, запас частьләр сатып алу һәм хезмәтләр өчен түләү, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, трактор өчен ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, хезмәтләр өчен түләү, чокырларны ремонтлау өчен вак таш сатып алу, хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга чыгымнар;

- Әккәрәй торак пунктында урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, урам утларына кулланылган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- Әккәрәй торак пунктында Азат итүче сугышчы һәйкәлен капиталь ремонтлау, проект-смета документациясен әзерләү, һәйкәл территориясен төзекләндерү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, хезмәтләр өчен түләү

**кабул ителгән дип танырга.**

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә: Әккәрәй авылы, Мәктәп урамы, 28 йорт, Чирмешән муниципаль районының рәсми интернет-сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Ивашкино авыл җирлеге башлыгы Ф.П. Андреев